

23 августта, Мордовия республикасынын Саранск шәһәрендә «Без бергә!» Ботенроссия яшьләр милли коллективлары ижаты марафоны Президент мәдәни инициативалар фонды ярдәмендә гамәлгә ашырыла торган Россия халыкларынын бердәмлеге һәм килешvе платформасы буларак vтте.
Чаранын тантаналы ачылышы алдыннан Мордовия Главасы Артём Здунов Совет мәйданында ачылган экспозицияләрне карады. Саранск шәһәре администрациясе бинасы фасады буйлап Мордовия Республикасынын «Ин матур авыл» традицион конкvреш, кәсеп һәм һонәрчелек урыннары тәкъдим ителде. Шәһәр халкы һәм фестиваль кунаклары арасында «Ижади авыллар» мәйданчыгы зур популярлык казанды.

Анда республиканын берничә торак пункты тәкъдим ителде: Краснослободск районынын Теньгушево, Иске Синдрово, Кочкурово районынын Подлесная Тавла, Ләмберә районынын Аксеново, Рузаевка районынын Левжа. Бу мәйданчыкта кунаклар Мордовия гореф-гадәтләре һәм йолалары белән таныштылар. Биредә татарларыбыз кvпләп яшәгән Ләмберә районынын Аксён авылы кvргәзмәсе матур һәм эчтәлекле иттереп оештырылган иде. Мордовия Республикасы халыклары конкvрешенен интерактив музей экспозицияләре гармунчыларнын, ансамбльләрнен, такмакчыларнын ижади баттллары, милли кием дефилесе белән vрелеп барды. Халыкны сокландырырлык иттереп vзләренен репертуарын Ләмберә районы Кривозерье мәдәният сарае «Хыял» ансамбле, Наилә Шәйхатдәр кызы Манеева житәкчелегендә, тәгъдим итте. Бигърәк дәртле такмаклары халыкка тынгы бирмәде - биеп алучылар да булды.  Шулай ук Ләмберәнен «Алмаз» мәдәни-спорт vзәге хезмәткәрләре югары зәвык белән милли мәдәният мирасын халыкка житкерделәр. Барлык чараларда актив булдылар.



«Без бергә!» Саранск шәһәрендә горләп vтте. Рузаевка районы ижат делегациясе составы арасында Татар Пешләсе мәдәният йорты «Матур кызлар» вокаль ансамбле, Наталья Анатольевна Чалдаева житәкчелегендә катнашып, тамашачыларга туган татар телендә жыр бvләк иттеләр.
Республика йорты янындагы мәйданда «Креатив индустрияләр» мәйданчыгы эшләде. «ТЕВ» («ЭШ») Россия Федерациясе субъектлары осталары катнашында тобәкара кvргәзмә - «Милли традицияләр» эшләнмәләре кvргәзмә-сату, мастер-класслар да vтте. Анда Мордовия Республикасы һәм Россия Федерациясенен башка тобәкләре осталарынын, дизайнерларынын һәм модельерларынын авторлык бизәнv әйберләре, аксессуарлары һәм киемнәре кvргәзмәсен кvрергә момкин булды. Шул исәптән Мордовиябез һәм башка регионнарда билгеле булган эшмәкәр Айдар Фаиль улы

Шафиев сабын ясау белән шогыльләнә һәм «Без бергә!» марафоны кысаларында оештырылган кvргәзмәсендә vзенен продукциясен тәгъдим итте. Рәхәтләнеп торле милләт вәкиле хәләл экосабыннарны сатып алдылар. Үз белеме,тырышлыгы, коче белән булдырган барлык экологик продукциясе «Хәләл» сертификаты таләпләренә җавап бирә. Әмма житештерvче яна технологияләрне сынап карый һәм производствосына кертә; продукнын сыйфатын даими vстерә. Ана матур эшләрендә унышлар телибез: татарларыбыз булдыра. Әйтеп китәргә кирәк, элек-электән Мордовиянен конбатыш район татарлары сабын пешерv белән мавыккан, хәтта Пенза сабын заводы белән элемтәдә булганнар.
«Без бергә!» марафоны кысаларында 1941-1945 еллардагы хәрби һәм хезмәт батырлыгы мемориаль музее янындагы Жинv мәйданында Мордовиянен патриотик проекты: ин зур маскировка челтәре vрv, яна кушылган территорияләр очен гуманитар ярдәм кvрсәтv һәм китаплар жыю, СВО сугышчыларына хатлар, волонтерлык проектлары, «Блиндаж» фотозонасы тематик мастер-класслар эшләде. Тагы А.С.Пушкин исемендәге милли китапханә янында Мордовия Республикасы китап нәшриятлары продукциясе кvргәзмә-презентациясе иде, сәнгать эшлекләре белән очрашулар, С.Д.Эрьзи исемендәге Мордовия сынлы сәнгать музее янындагы мәйданда «Хыял ясыйбыз» дигән яшь рәссамнарнын һәм «Театраль атмосфера» рәсем ясарга яратучыларнын ин массакvләм пленэрын кvреп булды. Мордовия Республикасынын әйдәп баручы театрлары актерларынын яшьләр очен спектакльләре һәм перформанслары «Театр - яшь һәм креатив»: театр сәнгатен яратучылар очен актерлардан мастер-класслар vтте. Мордовия Республикасы яшь рәссамнары һәм рәссамнар Берлеге әсәрләре кvргәзмәсе эчтәлекле иттереп оештырылган иде.

**Наилә НАСЫРОВА**